ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

2024 елның «08» ноябреннән — № 278

2025 елда Татарстан Ресаубликасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында

Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, укучыларны балансланган кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7 өлеше, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны тукландыруны тәэмин итү хакының нормативларын раслау турында» 2024 елның 16 сентябрендәге 789 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем алучыларны түләүсез кайнар азык белән тәэмин итүгә һәм аларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына белем алучыларның кайнар туклануының уртача хакын раслау турында» 2024 елның 12 сентябрендәге 777 номерлы карары, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елның 01 октябреннән алып Яңа Чишмә муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» 2020 елның 12 октябрендәге 257 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының аз тәэмин ителгән гаиләләреннән белем алучыларны бушлай тукландыруны тәэмин итү тәртибе турында нигезләмә

нигезендә, Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1.1 Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 класс укучыларын уртача бәясе 69,43 сум булган кайнар тукландыру оештырырга;

1.2 Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының 5-11 сыйныф укучыларын һәр уку көненә 9 сум 60 тиен күләмендә субсидиядән һәм ата-аналар түләвеннән торган суммага кайнар туклandыруны оештырырга;

1.3 гаиләнең бер әгъзасына туры килгән Татарстан Республикасы буенча 50 сум күләмендә билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган аз керемле гаиләләрдән булган укучылар өчен бсубсидияне исәпкә алып, җирле бюджет акчалары исәбеннән бушлай кайнар иртәнге ашлар оештырырга;

1.4. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән (ОВЗ) укучыларны җирле бюджет акчалары хисабына, шул исәптән субсидияләрне дә кертеп, ике тапкыр бушлай ашатуны оештырырга:

1-4 сыйныфлары өчен бәясе 69,43 сумлык и 25 сумлык;

5-11 сыйныфлар өчен бәясе 50 сумлык һәм 25 сумлык.

1.5. Ата-аналары яки законлы вәкилләре махсус хәрби операциядә катнаша торган гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын җирле бюджет акчалары хисабына, шул исәптән субсидияләрне дә кертеп, ике тапкыр бушлай ашатуны оештырырга:

1-4 сыйныфлары өчен бәясе 69,43 сумлык и 25 сумлык;

5-11 сыйныфлар өчен бәясе 50 сумлык һәм 25 сумлык.

1.6. 5 көн эчендә бушлай туклandыру өчен 1.2 пунктта күрсәтелгән категорияләргә кергән укучылар исемлеген бирергә.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына аз керемле гаиләләрдән булган балаларны бушлай туклandыруны оештыру чыгымнарын Татарстан Республикасы Яңа Чишмә

муниципаль районы бюджеты хисабына финанслауны башкарырга тәкъдим итәргә.

3. Мәктәп укучыларын кайнар аш белән тәэмин итүче гомуми белем бирү учреждениеләре һәм башка предприятиеләр җитәкчеләренә:

3.1. Мәктәп ашханәләрен сыйфатлы азык-төлек белән өзлексез тәэмин итәргә.

3.2. Витаминнар, микронутриентлар белән баетылган төп туклыклы матдәләрне карап тоту буенча балансланган иртәнге һәм төшке ашларның нормаларын һәм сыйфатын исәпкә алуны һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

3.3. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыруны, санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм «гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучылар туклануын оештыруга санитария-эпидемиология таләпләре» СанПин 2.4.5.2409-08 нормативлары нигезендә, «Санитар кагыйдәләрне үтәү һәм санитария-эпидемияләргә каршы (профилактика) чаралар үтәүгә производство контролен оештыру һәм үткәрү» СП 1.1.1058-01 номерлы СанПиН нигезендә производство контролен башкарырга.

4. Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларына түләүсез туклануны оештыру буенча социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан һәм, билгеләгән форматларга туры китереп, Социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы аша алынырга мөмкин».

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru , «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/ novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

7. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2023 елның 19 октябрендәге 238 номерлы карары (2023 елның 30 ноябрендәге 269 номерлы, 2024 елның 20 февралендәге 71 номерлы карарлардагы үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов